ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.01.2024 г. Заинск № 54

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 сентябрендәге 557 номерлы “Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектының планлаштырылган төзелеше турында белдерүдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир участогында урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 10 сентябрендәге 557 номерлы “Индивидуаль торак төзелеше яки бакча йорты объектының планлаштырылган төзелеше турында белдерүдә күрсәтелгән параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир участогында урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.5.1 пунктында «шәхси торак төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү» сүзләрен «шәхси торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү» сүзләре белән алыштырырга (2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп шәхси торак төзелеше объектларын төзүдән тыш күп фатирлы йортлар һәм башка күчемсез милек объектлары төзү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында)»;

1.2. 1.5 пунктның 3 абзацында «гражданнарның хокукларын яклау буенча иҗтимагый-хокукый компания - төзүчеләр банкротлыкка чыкканда өлешләп төзүдә катнашучылар һәм» сүзләрен “Территорияләрне үстерү фонды" иҗтимагый-хокукый компаниясе һәм” сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең Икътисади үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшкуарлыкка ярдәм итү буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

О.В. Усик
7-14-14